ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 декабрь, 2022 ел № 18/12

Җәмәгать тыңлауларын һәм иҗтимагый фикер алышуларны оештыру өлешендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 289-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 19, 28 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 18/20, 2019 елның 23 маендагы 31/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия Проектны, шулай ук җәмәгать тыңлаулары уздыру турындагы хәбәрләрне рәсми бастырып чыгару чыганакларында бастыруны һәм аны шәһәрнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап буенча җәмәгать тыңлаулары уздыру датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеген үстерү планнары һәм программалары, шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары уздыру датасына кадщр 20 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыруны тәэмин итә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт өстәргә:

«11.1 Физик һәм юридик затлар, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр җәмәгать тыңлауларына чыгарылган Проектка искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен Россия

Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә Бердәм портал федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган Проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр физик һәм юридик затлар, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып, анда авторизация үткәннән соң, Бердәм портал кулланып кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү җәмәгать тыңлаулары турында мәгълүматны һәм җәмәгать тыңлауларына чыгарылган Проектны бастырып чыгарган көннән башлана һәм җәмәгать тыңлаулары уздыру көненә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җирле үзидарә органының шәхси кабинетына җибәрелә.»;

3) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Комиссия, йомгаклау беркетмәсе кабул ителгән көннән алып, биш календарь көн эчендә аны рәсми массакүләм мәгълүмат чыганакларында бастырып чыгаруны, шулай ук аны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм Бердәм порталда урнаштыруны тәэмин итә» .

2. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча җәмәгать тыңлаулары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 10 июлендәге 31/14 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2015 елның 17 июнендәге 40/17, 2015 елның 17 декабрендәге 4/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктта «шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыру» сүзләрен өстәргә;

2) 12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Комиссия рәсми бастырып чыгару чыганакларында җәмәгать тыңлаулары уздыру турындагы хәбәрне бастырып чыгаруны һәм аны Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә, җәмәгать тыңлаулары уздыру датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, урнаштыруны тәэмин итә. Җәмәгать тыңлаулары уздыру турындагы хәбәрдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:»;

3) түбәндәге эчтәлекле 13.1 пункт өстәргә:

«13.1 Физик һәм юридик затлар, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр шәһәр Уставы проекты буенча искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә Бердәм портал аша җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган шәһәр Уставы проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр физик һәм юридик затлар, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик

хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып, анда авторизация үткәннән соң Бердәм портал кулланып кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү җәмәгать тыңлаулары турында мәгълүматны һәм җәмәгать тыңлауларына чыгарылган шәһәр Уставы проектын бастырып чыгарган көннән башлана һәм җәмәгать тыңлаулары уздыру көненә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җирле үзидарә органының шәхси кабинетына җибәрелә.»;

4) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Комиссия бәяләмә кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә аны рәсми бастырып чыгару чыганакларында бастырып чыгаруны, шулай ук аны Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм Бердәм порталда урнаштыруны тәэмин итә.»;

3. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу яйсә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2019 елның 7 октябрендәге 33/10, 2020 елның 28 маендагы 39/10, 2021 елның 4 августындагы 8/9, 2022 елның 22 августындагы 16/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Җәмәгать тыңлаулары уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында мәглүмат, җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, җәмәгать тыңлауларын үткәрү көненә кадәр 20 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында басылып чыгарга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында www.nabchelny.ru (алга таба - рәсми сайт), шулай ук «Бердәм дәүләт порталы һәм муниципаль функцияләр» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга тиеш.»;

2) 21 пунктның 2 пунктчасында «(алга таба - «Интернет)» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә Бердәм порталда» сүзләрен өстәргә;

3) 22 пунктның 2 пунктчасында «рәсми сайтта» сүзләреннән соң «, мәгълүмат системаларында» сүзләрен өстәргә;

4) 24 пунктның икенче абзацында «рәсми сайт турында» сүзләрен «рәсми сайт һәм мәгълүмат системалары» сүзләренә алыштырырга;

5) 28 пунктта

- 1 пунктчада «бер айдан да артык була алмый» сүзләрен «кимендә бер ай һәм өч айдан да артык булмаган» сүзләренә алыштырырга;

- 2 пунктчада «бер айдан да артык була алмый» сүзләрен «кимендә бер ай һәм өч айдан да артык булмаган» сүзләренә алыштырырга.

6) 35 пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Җәмәгать тыңлауларына яисә иҗтимагый  фикер алышуга чыгарылган проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр  җәмәгать тыңлауларына яисә иҗтимагый  фикер алышуда катнашучылар тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып, анда авторизациядән соң Бердәм портал кулланып  кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү җәмәгать тыңлаулары турында мәгълүматны һәм җәмәгать тыңлауларына чыгарылган  проект һәм мәглүмати материалларны бастырып чыгарган көннән башлана һәм җәмәгать тыңлаулары уздыру көненә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җирле үзидарә органының шәхси кабинетына җибәрелә.»;

7) 67 пунктта «һәм Бердәм порталда» сүзләрен өстәргә.

4. Шәһәр Советының « Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм уздыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 1 августындагы 32/10 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктта «шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыру» сүзләрен өстәргә;

2) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны урнаштыру чорында физик һәм юридик затлар, иҗтимагый оешмалар карала торган проект буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язма рәвештә Комиссия адресына, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә  Бердәм портал ярдәмендә җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җәмәгать тыңлауларына яисә иҗтимагый  фикер алышуда катнашучылар тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып, анда авторизация үткәннән соң Бердәм портал кулланып  кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү җәмәгать тыңлаулары турында мәгълүматны һәм җәмәгать тыңлауларына чыгарылган проектны бастырып чыгарган көннән башлана һәм җәмәгать тыңлаулары уздыру көненә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җирле үзидарә органының шәхси кабинетына җибәрелә.»;

3) 42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турындагы бәяләмә аңа кул куйганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча рәсми чыганакларда бастырып чыгарылырга

һәм Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, Бердәм порталда урнаштырылырга тиеш.».

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев